**Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлегенең Алан торак пунктының гражданнар җыены буенча**

# **КАРАРЫ**

**2019 елның 22 ноябре** **Алан авылы**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Алан авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, 2019 елның 22 ноябрендә Алан торак пунктында узган гражданнар җыенының тавыш бирү нәтиҗәләре белән хисап комиссиясе беркетмәсе төзелде, «Сез ризамы, Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлегенең Алан торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда гражданнарның 500 сум күләмендә үзара салымын кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны чираттагы эшләрне башкару буенча юнәлтергә:

- Алан авылында урам утларын, яктырткычларны, махсус җиһазларны сатып алу, урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү;
- Алан авылындагы Октябрь, Пионер, Мәктәп, Комсомол урамнарындагы вак таш җәелгән юлларны ремонтлау (сатып алу, вак таш җәю, килешү буенча эшләү өчен түләү);
- Алан авылында юлларны кардан чистарту;
- Алан авылы зираты коймаларын буяу өчен материал сатып алу;
- Алан авылында кое ремонты (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Тәмтебаш елгасы буен вак куаклардан чистарту;
- Алан авылында урам исемнәре, йорт номерлары күрсәткечләрен әзерләү һәм урнаштыру?»

« РИЗА» «КАРШЫ»?».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында хисап комиссиясе беркетмәсе нигезендә:

Җыенда катнашучыларның сайлау хокукына ия булучылары исемлегенә 369 кеше кертелгән;

җыенда катнашучыларның тавыш бирүчеләре саны 186 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар өчен түбәндәгеләр билгеләнде:

гражданнар җыенында катнашкан 186 кеше «Риза» позициясе өчен тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен беркем дә тавыш бирмәде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1.Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлегенең Алан торак пунктында гражданнар җыены булып узды, гражданнар җыены нәтиҗәләре-дөрес.

2.Мәсьәлә буенча карар кабул итәргә: «Сез ризамы, Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлегенең Алан торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда гражданнарның 500 сум күләмендә үзара салымын кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны чираттагы эшләрне башкару буенча юнәлтергә:

- Алан авылында урам утларын, яктырткычларны, махсус җиһазларны сатып алу, урнаштыру, килешүе буенча эшләр өчен түләү;

-Алан авылындагы Октябрь, Пионер, Мәктәп, Комсомол урамнарындагы вак таш җәелгән юлларны ремонтлау (сатып алу, вак таш җәю, килешү буенча эшләү өчен түләү);

- Алан авылында юлларны кардан чистарту;

Алан авылы зираты коймаларын буяу өчен материал сатып алу;

- Алан авылында кое ремонты (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Тәмтәбаш елгасы буен вак куаклардан чистарту;

- Алан авылында урам исемнәре, йорт номерлары күрсәткечләрен әзерләү һәм урнаштыру-кабул ителгән.

3. Җыен нәтиҗәләре турында әлеге карарны, гамәлдәге законнар нигезендә, шул исәптән, мәгълүмат стендларында һәм Интернет челтәрендә Алан авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Алан авыл җирлеге Башлыгы: Ә.Г.Хаҗиев

СОВЕТ АЛАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ